ГОСУДАРСТВЕННАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОБЕСПЕЧЕНИЮ
ГОСУДАРСТВЕННОГО КОНТРОЛЯ
ЗА ПРОИЗВОДСТВОМ, ОБОРОТОМ И
КАЧЕСТВОМ ЭТИЛОВОГО СПИРТА,
АЛКОГОЛЬНОЙ ПРОДУКЦИИ
И ЗАЩИТЕ ПРАВ ПОТРЕБИТЕЛЕЙ
(Госалкогольинспекция Республики Татарстан)

Х. Такташа ул., 94, а/я 44, Казань, 420107

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ЭТИЛ СПИРТЫ, АЛКОГОЛЬЛЕ
ПРОДУКЦИЯ ҖИТЕШТЕРҮ, ӘЙЛӘНЕШЕ
һӘМ СЫЙФАТЫ ӨЛКӘСЕНДӘ ДӘҮЛӘТ
КОНТРОЛЕН ТӘЭМИН ИТҮ һӘМ
КУЛЛАНУЧЫЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫН
ЯКЛАУ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ИНСПЕКЦИЯСЕ
(Татарстан Республикасы дәүләт алкоголь
инспекциясе)

һ.Такташ урамы, 94 нче йорт, Казан шәһәре, 420107

тел. (843) 278-92-00, факс (843) 278-91-92, e-mail: gosalcogol@tatar.ru, http://gosalcogol.tatar.ru,
ОКПО 42151664, ОГРН 1021602865239, ИНН/КПП 1654025044/165901001

# БОЕРЫК

08.09.2025 Казан ш. № 10-07/61

Татарстан Республикасы Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүгә, аларның әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен һәм кулланучылар хокукларын яклауны тәэмин итү буенча Дәүләт инспекциясенең дәүләти гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында

1. Татарстан Республикасы Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүгә, аларның әйләнешенә һәм сыйфатына дәүләт контролен һәм кулланучылар хокукларын яклауны тәэмин итү буенча Дәүләт инспекциясенең 2016 елның 23 маендагы 12-07/38 номерлы дәүләти гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу Комиссиясе составына (Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең 2018 елның 26 июлендәге 12-07/130, 2023 елның 13 мартындагы 10-07/29 һәм 2024 елның 25 июлендәге 10-07/94 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Комиссия составыннан Романов Павел Николаевичны чыгарырга;

Комиссия составына Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең финанс контроле бүлеге башлыгы, Комиссия әгъзасы Хузина Рима Нурулловнаны кертергә.

2. Административ һәм суд практикасы бүлегенә бу Боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында теркәүгә алуны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи затка әлеге Боерыкны Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Бу Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Җитәкче** **Җ.Й. Әхмәтханов**